КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 3 сентябрь г.Казань № 659

«Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль мөлкәтен исәпкә алу һәм аның белән идарә итү буенча бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлегендә мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдалану, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын планлаштыру, булдыру, үстерү, модернизацияләү, эксплуатацияләү чараларын координацияләү тәртибе турында» 2015 ел, 30 май, 387 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте һәм муниципаль мөлкәт белән идарә итүне гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль мөлкәтен исәпкә алу һәм аның белән идарә итү буенча бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – Система) булдырырга.

2. Бу карарга теркәлгән «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль мөлкәтен исәпкә алу һәм аның белән идарә итү буенча бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне расларга.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгын – Система булдыруны, аны үстерүне һәм эксплуатацияләүне тәэмин итүгә вәкаләтле республика башкарма хакимият органы итеп;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгын – Системадагы Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында мәгълүматка ия, Системаны эксплуатацияләүгә вәкаләтле республика башкарма хакимият органы итеп;

«Татарстан Республикасының Цифрлы трансформация үзәге» дәүләт казна учреждениесен – Системаны һәм сервер җиһазын эшкә сәләтле хәлдә тотуны тәэмин итүче, Системадан файдалану мөмкинлеген бирүче дәүләт учреждениесе итеп.

4. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына Системаны эксплуатацияләүгә вәкаләтле органнарны һәм Системада булган муниципаль мөлкәт турында мәгълүматка ия булучыларны билгеләүне тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына һәм аларның ведомство буйсынуындагы оешмаларга, әлеге карар белән расланган Система турындагы нигезләмәгә таянып, Системада мәгълүматлар, документлар, материаллар булдыруны һәм урнаштыруны тәэмин итәргә.

6. Федераль башкарма хакимият органнарына һәм аларның территориаль органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына, тиешле мөлкәт хокукы яки закон нигезендә муниципаль мөлкәткә ия булган оешмаларга, индивидуаль эшмәкәрләргә һәм физик затларга әлеге карар белән расланган Система турындагы нигезләмә таянып Системадан файдалануны тәкъдим итәргә.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны түбәндәгеләргә йөкләргә.

Системаны булдыру, эксплуатацияләү, үстерү һәм аның мәгълүмати куркынычсызлыгын (модернизацияләүне, башка мәгълүмат системалары белән интеграцияләүне, Системаны алып бару эшләрен координацияләүне кертеп) тәэмин итү өлешендә – Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына;

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан Системада дөрес, тулы һәм актуаль мәгълүматлар, документлар, материаллар булдырылуга һәм урнаштырылуга, Системаның функциональ кулланылышына, методологик тәэмин ителешенә, шулай ук Системаны эксплуатацияләүне мониторинглауга кагылышлы өлештә – Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 3 сентябрь, 659 нчы
карары белән расланды

«Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль мөлкәтен исәпкә алу һәм аның белән идарә итү буенча бердәм мәгълүмат системасы»
Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында
нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль мөлкәтен исәпкә алу һәм аның белән идарә итү буенча бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – Система) максатларын һәм бурычларын, эшчәнлеген оештыру һәм үстерү тәртибен билгели.

1.2. Система дәүләт мәгълүмат системасы булып тора һәм Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне исәпкә алуны, аның белән идарә итүне һәм эш итүне тәэмин итү өчен кулланыла.

1.3. Системаның максатлары:

Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте һәм муниципаль мөлкәт белән идарә итүнең бердәм методологиясен тәэмин итү;

Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте һәм муниципаль мөлкәт белән идарә итү һәм аның белән эш итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү срокларын оптимальләштерү;

идарә итү процессларын комплекслы автоматлаштыру һәм идарә өлкәсендә документлар әйләнешен электрон формага күчерү юлы белән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне куллану нәтиҗәлелеген арттыру;

Татарстан Республикасы бюджет системасына керемнәр керүне арттыру.

1.4. Система түбәндәге бурычларны хәл итү өчен билгеләнгән:

Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте һәм муниципаль мөлкәт белән идарә итү системасын цифрлы трансформацияләү, шул исәптән:

объектлар (бердәм объект, дәүләтнең чикләнмәгән милкендәге җирләр буларак исәпкә алына торган җир кишәрлекләре яки аларның билгеләнешенә туры килми торган зыянсыз күчереп йөртү мөмкин булмаган, җир белән нык бәйләнгән объектлар, шул исәптән биналар, корылмалар, төзелеше тәгәлләнмәгән объектлар, бердәм күчемсез комплекслар, бүлмәләр, машина урыннары, һава, диңгез суднолары, эчке йөзү судноларын, хуҗалык җәмгыятенең, ширкәтнең устав (җыелма) капиталындагы акцияләр, өлешләр (кертемнәр), кыйммәте иң чик күрсәткечкә тигез яки аннан артып китә торган күчемле мөлкәт (кыйммәте иң чик күрсәткечкә тигез яки артып китә торган аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне дә кертеп), транспорт чаралары, матди булмаган активлар, күчемсез һәм (яки) күчемле мөлкәт объектына гомуми өлешле милек хокукындагы өлешләр, бер берәмлекнең башлангыч кыйммәте

иң чик күрсәткечтән кимрәк булган күчемле мөлкәт, шулай ук бер берәмлекнең башлангыч кыйммәте иң чик күрсәткеченнән һәм әйләнеш активларыннан кимрәк булган аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт (аларның кыйммәтенә карамастан)) реестрларын алып бару;

Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте яки муниципаль мөлкәт тиешле әйбер хокукы яки закон нигезендә караган субъектлар (юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр һәм физик затлар) реестрларын алып бару;

документлар (Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне исәпкә алу, аның белән идарә итү һәм эш итү процессларын тәэмин итә торган боеру характерындагы документлар, шартнамәләр, килешүләр, өстәмә килешүләр, актлар, өземтәләр, гаризалар һәм башка документлар) реестрын алып бару;

Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте һәм муниципаль мөлкәт белән идарә итү процессларын автоматлаштыру;

Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне исәпкә алу, алар белән идарә итү һәм эш итү буенча алыш-бирешләргә администраторлык итү;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтелгәндә һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә үзара мәгълүмат алмашуны тәэмин итү.

## II. Система кысаларында Үзара мәгълүмат алмашуда катнашучылар

2.1. Система кысаларында Үзара мәгълүмат алмашуда катнашучылар (алга таба – Үзара мәгълүмат алмашуда катнашучылар):

Системаның операторы һәм функциональ заказчысы – Системадагы Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында мәгълүматка ия булучы, Системаны эксплуатацияләүгә вәкаләтле республика башкарма хакимият органы;

Системаның муниципаль операторлары – Системаны эксплуатацияләүгә вәкаләтле дә һәм Системадагы муниципаль мөлкәт турында мәгълүматка ия булучы да итеп билгеләнгән Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары;

Системаның техник операторы – Системаның сервер җиһазын һәм программа тәэминатын эшкә сәләтле хәлдә тотуны тәэмин итүче, Системадан файдалану мөмкинлеге бирүче дәүләт учреждениесе;

вәкаләтле орган – Системаны булдыру, эксплуатацияләү һәм үстерүне тәэмин итүгә вәкаләтле республика башкарма хакимият органы;

Системадан файдаланучылар – федераль башкарма хакимият органнары һәм аларның территориаль органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм аларның ведомство буйсынуындагы оешмалар, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте яки муниципаль мөлкәт тиешле әйбер хокукы буенча яки закон нигезендә караган физик затлар һәм юридик затлар.

2.2. Системаның операторы һәм функциональ заказчысы түбәндәгеләрне

тәэмин итә:

Системаны эксплуатацияләүне, шул исәптән Системадагы мәгълүматны эшкәртү буенча;

үз вәкаләтләре кысаларында Системада белешмәләр, документлар, материаллар булдыру һәм урнаштыруны, шулай ук Системада булдырылган һәм урнаштырылган белешмәләр, документлар, материаллар арасында бәйләнешләр урнаштыруны;

файдалану хокуклары бүленешенең роль моделен кулланып, Система операторы һәм функциональ заказчысы хезмәткәрләренә Системада булдырылган һәм урнаштырылган белешмәләрдән, документлардан, материаллардан файдалану хокукларын билгеләүне;

шәхси мәгълүматларны эшкәртү һәм мәгълүмат куркынычсызлыгы өлкәсендә закон таләпләрен үтәп, Системадагы шәхси мәгълүматларны эшкәртүне;

Системада белешмәләр, документлар, материаллар булдыру һәм урнаштыру мәсьәләләре буенча Системаның муниципаль операторлары эшчәнлеген координацияләүне;

Системаны модификацияләү (модернизацияләү), аның эшкә сәләтен (эшләвен) тәэмин итү, Системадагы мәгълүматны саклау максатларында һәм Системаның эшчәнлегенә бәйле башка максатларда техник таләпләр проектларын, техник биремнәрне, спецификацияләрне һәм товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуны, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен файдалануның махсус хокукын һәм (яки) хокукын сатып алу өчен кирәкле башка документлар килештерүне;

Системаның техник операторы адресына Системаның эшендә җитешсезлекләр турында хәбәрләр һәм Системаны үстерү буенча тәкъдимнәр җибәрүне.

2.3. Системаның муниципаль операторы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

Системаны эксплуатацияләү өчен кирәкле шартларны, шул исәптән Системадагы мәгълүматны эшкәртү буенча;

үз вәкаләтләре кысаларында Системада белешмәләр, документлар һәм материаллар булдыру һәм урнаштыруны, шулай ук Системада булдырылган һәм урнаштырылган белешмәләр, документлар, материаллар арасында бәйләнешләр урнаштыруны;

файдалану хокуклары бүленешенең роль моделен кулланып, Системаның муниципаль операторы хезмәткәрләренә Системада булдырылган һәм урнаштырылган белешмәләрдән, документлардан, материаллардан файдалану хокукларын билгеләүне;

шәхси мәгълүматларны эшкәртү һәм мәгълүмат куркынычсызлыгы өлкәсендә закон таләпләрен үтәп, Системадагы шәхси мәгълүматларны эшкәртүне;

Системаның техник операторы адресына Система эшендәге җитешсезлекләр турында хәбәрләр һәм Системаны үстерү турында тәкъдимнәр җибәрүне (Системаның операторы һәм функциональ заказчысы белән килештереп).

2.4. Системаның техник операторы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

Системаны һәм аның элементларын булдыру, модификацияләү (модернизацияләү), аларның эшкә сәләтен (эшләвен) тәэмин итү, Системадагы мәгълүматны саклау максатларында һәм Системаның һәм аның элементларының эшләвенә бәйле башка максатларда товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләреннән файдалануның махсус хокукын һәм (яки)

файдалану хокукын сатып алуны;

Системаны эксплуатацияләүгә һәм аның эшләвен тәэмин итеп торуга, шулай ук техник чараларга, элемтә каналларына, Системадагы мәгълүматны саклый торган техник һәм программа чараларына техник биремнәр һәм (яки) техник таләпләр әзерләүне;

техник (шулай ук эксплуатация) документация таләпләре нигезендә Системаның тәүлек әйләнәсе эшкә сәләтен булдыруны;

Системада булдырылган һәм урнаштырылган белешмәләргә, документларга, материалларга карата күп кулланучылар файдалану режимы булуны;

Системада булдырылган һәм урнаштырылган белешмәләр, документлар, материалларның, шулай ук Системаның эшкә сәләте бозылганнан соң программа чараларының резерв күчермәсен алу, аларны саклау һәм торгызуны;

Системаның сервер җиһазын һәм программа тәэминатын эшкә сәләтле хәлдә тоту буенча башка чараларны.

2.5. Вәкаләтле орган түбәндәгеләрне тәэмин итә:

Системаны булдыру, эксплуатацияләү һәм үстерүне (модернизацияләүне дә кертеп);

Системаны эксплуатацияләү һәм үстерү буенча оештыру, норматив һәм методик яктан тәэминителеше булуны;

башка мәгълүмат системалары белән интеграцияләүне;

Системадагы мәгълүматны саклый торган техник һәм программа чаралары булуны;

мәгълүмат куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, Системадагы мәгълүматның сакланышы буенча мәгълүмат куркынычсызлыгын;

Системаны алып бару эшләрен башкаруны координацияләүне.

2.6. Системадан файдаланучы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

үз компетенцияләре чикләрендә белешмәләр, документлар, материалларны җыю, документлаштыру, эшкәртү, системалаштыру, исәпкә алу һәм электрон рәвештә җибәрү, Системада булдыру һәм урнаштыруны;

Системада булдырылган һәм урнаштырылган белешмәләр, документлар, материаллар дөреслеген, тулылыгын һәм актуальлеген;

мәгълүмат куркынычсызлыгының оештыру һәм техник таләпләре, шул исәптән шәхси мәгълүматлар белән эшләгәндә үтәлешен.

## III. Системаның структурасы һәм функциональлеге

3.1. Система модульле структурага ия һәм функциональ ярдәмче системалардан һәм Системаның эшен тәэмин итә торган ярдәмче системалардан тора, шулай ук Системаның операторы һәм функциональ заказчысы, Системаның муниципаль операторларының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү турында гаризалар кабул итү каналы булып торган «Шәхси кабинет» функциональ компонентын үз эченә ала.

3.2. Системада булдырылган һәм урнаштырылган белешмәләр, документлар, материаллар составы Системаның операторы һәм функциональ заказчысы

тарафыннан билгеләнә.

3.3. Системада Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте һәм муниципаль мөлкәт объектлары турында мәгълүматларның бертөрлелеген һәм чагыштырырлык булуын тәэмин итү максатларында объектларга һәм субъектларга реестр номерлары биргәндә бердәм үтә күренмәле автомат номер бирү кулланыла.

3.4. Үзара мәгълүмат алмашуда катнашучылар әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән шартларда Системаның эшләвен тәэмин итә.

3.5. Система модификацияләнергә (модернизацияләнергә) мөмкин.

3.6. Системада Үзара мәгълүмат алмашуда катнашучылар арасында мәгълүмат алмашу, шул исәптән электрон төрдә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү һәм дәүләт функцияләрен һәм муниципаль функцияләрне башкару өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктураны кулланып, шулай ук ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан файдалану юлы белән гамәлгә ашырыла.

3.7. Системаның башка мәгълүмат системалары белән интеграция механизмнары бар.

3.8. Системада булдырылган һәм урнаштырылган белешмәләр, документлар, материаллар конфиденциаль һәм юридик әһәмияткә ия булып тора.

Системада булдырылган һәм урнаштырылган белешмәләргә, документларга, материалларга юридик әһәмият бирү максатларында көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланыла һәм документларны имзалаганда көчәйтелгән квалификацияле электрон имза тикшерү ачкычының сертификаты тикшерелә.

## IV. Система кысаларында үзара мәгълүмат алмашу

4.1. Системада Үзара мәгълүмат алмашуда катнашучылар арасында мәгълүмат алмашу электрон формада гамәлгә ашырыла.

4.2. Системаның операторына һәм функциональ заказчысына Системаның муниципаль операторлары һәм Системадан файдаланучылар тарафыннан булдырылган һәм урнаштырылган Система белешмәләреннән, документларыннан, материалларыннан файдалану мөмкинлеге аларны үзгәртү мөмкинлегеннән башка бирелә.

4.3. Системаның техник операторына Системаның барлык компонентлары буенча Системаның эш параметрлары метрикаларыннан, шулай ук Системадан файдалану нәтиҗәлелеген һәм динамикасын анализлау өчен агрегатланган мәгълүматлардан файдалану мөмкинлеге бирелә.

4.4. Системада белешмәләр, документлар, материаллар булдыру һәм урнаштыру, шулай ук аларны теркәү һәм исәпкә алу электрон формада башкарыла.

## V. Системадан файдалану мөмкинлеге бирүгә карата таләпләр

5.1. Системадан файдалану мөмкинлеге бирү шартлары:

Системаның операторы һәм функциональ заказчысы һәм Системаның муниципаль операторы хезмәткәренең «govtatar» доменында «@tatar.ru» корпоратив

электрон почтасын кулланучыны исәпкә алу язмасы булу;

техник мөмкинлекләр булу: «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташкан, җиһазландырылган эш урыны булу;

мәгълүмат куркынычсызлыгы таләпләре үтәлешен тәэмин итү.

5.2. Системаның операторы һәм функциональ заказчысы һәм Системаның муниципаль операторы Системадан хезмәткәрнең файдалану мөмкинлеге өчен заявка формалаштыра. Заявкада фамилия, исем, атасының исеме (булганда), «@tatar.ru» корпоратив электрон почта адресы, роль, файдалану хокукы (уку, төзәтмә кертү, бетерү) күрсәтелә. Формалаштырылган заявка Системаның техник операторына җибәрелә.

Системаның техник операторы биш эш көне эчендә хезмәткәргә Системадан файдалану мөмкинлеге бирүне тәэмин итә.

Системадан файдалану мөмкинлеге бирелгәннән соң, хезмәткәрнең авторизация үтү мөмкинлеге барлыкка килә.

5.3. Файдаланучыларның «Шәхси кабинет» функциональ компонентыннан файдалану мөмкинлеге «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – идентификация һәм авторизация системасы) сервисыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

5.4. «Шәхси кабинет» функциональ компонентыннан файдалану мөмкинлеге бирү шартлары:

идентификация һәм авторизация системасының юридик затлар регистрында яисә идентификация һәм авторизация системасының дәүләт хакимияте органы регистрында файдаланучының теркәлгән булуы;

«Шәхси кабинет» функциональ компонентыннан файдалану мөмкинлеге бирелгән файдаланучы хезмәткәренең идентификация һәм авторизация системасындагы оешмага фактта кушылуы;

техник мөмкинлек булу;

мәгълүмат куркынычсызлыгы таләпләре үтәлешен тәэмин итү.

## VI. Системада эшләгәндә мәгълүмат куркынычсызлыгын тәэмин итүгә карата таләпләр

6.1. Система Техник һәм экспорт контроле федераль хезмәтенең «Дәүләт мәгълүмат системаларындагы дәүләт серен тәшкил итмәгән мәгълүматны саклау турындагы таләпләрне раслау хакында» 2013 елның 11 февралендәге 17 номерлы боерыгы нигезендә аттестацияләргә тиеш.

6.2. Үзара мәгълүмат алмашуда катнашучылар Системаны аттестацияләүгә карата таләпләр нигезендә Системада эшләгәндә үз эш урыннарында мәгълүматның сакланышын тәэмин итәргә тиеш.

6.3. Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә һәм саклауга карата мәгълүмат куркынычсызлыгы буенча таләпләр бозылган өчен Үзара мәгълүмат алмашуда катнашучылар законнарда каралган тәртиптә җавап бирә.

6.4. Үзара мәгълүмат алмашуда катнашучыларга Системадан файдалану өчен авторизацияләү чараларын (шул исәптән логиннарны һәм парольләрне) өченче затларга бирү тыела.

6.5. Системаның операторы һәм функциональ заказчысы һәм Системаның муниципаль операторлары Системада белешмәләр, документлар, материалларны булдыру һәм урнаштыру дөреслеге, тулылыгы һәм актуальлеге өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

6.6. Системадан файдаланучылар Системада урнаштыру өчен белешмәләр, документлар, материаллар җибәрү дөреслеге, тулылыгы һәм актуальлеге өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

6.7. Системадагы мәгълүматның сакланышын тәэмин итү өчен Системаның операторы һәм функциональ заказчысы тарафыннан түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

хокуксыз файдалану, бетерү, модификацияләү, блоклау, күчермә алу, бирү, таратудан, шулай ук башка хокукый булмаган гамәлләрдән сакланырга тиешле мәгълүматны билгеләү;

мәгълүматны саклау турындагы таләпләр нигезендә Системаны классификацияләү.

6.8. Системадагы мәгълүматны саклау максатларында Системаның техник операторы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

Системада мәгълүмат куркынычсызлыгын бозуга китерә алган мәгълүмат куркынычсызлыгына янауларны билгеләү һәм алар нигезендә мәгълүмат куркынычсызлыгына янаулар моделен эшләү;

Системадагы мәгълүматны саклау буенча мәгълүмат системасына (ярдәмче системасына) карата таләпләрне билгеләү.

6.9. Вәкаләтле орган мәгълүматны саклауга карата билгеләнгән таләпләрнең үтәлешенә кагылышлы өлештә иминлекне тәэмин итү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы белән һәм техник разведкаларга һәм мәгълүматны техник саклауга каршы тору өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы белән мәгълүматны саклау системасына техник биремне һәм мәгълүмат куркынычсызлыгына янаулар моделен әзерләүне һәм килештерүне оештыра.

______________________________